**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең**
**Иске Минзәләбаш авылы**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№1** **16.11.2019**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылы халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 16 ноябрендә "Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I,II төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәр балигъ булган гражданнан 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

- Иске Минзәләбаш авылының Октябрьнең 60 еллыгы урамы, Октябрьнең 50 еллыгы урамына вак таш җәю;
- Иске Минзәләбаш авылында яктырткычлар алыштыру;
- Беларусь 320.4 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;;
- Иске Минзәләбаш авылы обелискы өчен Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемнәре язылган мемориаль такта сатып алу ;

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

2019 елның 16 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 511 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 280 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 280 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында узган халык җыенын узган дип санарга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча: " Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I,II төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш һәр балигъ булган гражданнан 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

- Иске Минзәләбаш авылының Октябрьнең 60 еллыгы урамы, Октябрьнең 50 еллыгы урамына вак таш җәю;
- Иске Минзәләбаш авылында яктырткычлар алыштыру;
- Беларусь 320.4 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Иске Минзәләбаш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май) уткәрү өчен бүләкләр сатып алу;;
- Иске Минзәләбаш авылы обелискы өчен Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемнәре язылган мемориаль такта сатып алу ;

ӘЙЕ ЮК»

кабул ителгән карарны ( "әйе" – 280 тавыш, "юк" – 0 тавыш) кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Иске Минзәләбаш авылы, Ленин урамы, 58 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ә.Р.Мияссарова